КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 апрель, 281 нче; 2018 ел, 14 июнь, 481 нче; 2018 ел, 17 октябрь, 940 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1320 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1087 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктка «нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве, төп хезмәт бурычларына юрист яки башкаручы буларак хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, аларга виза салу керә торган, югары юридик белемгә ия булган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләнә торган түләү (юридик эш өчен өстәмә түләү), профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта:

3 пунктчада «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктчада «(җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп оештырганда муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы вазыйфасына билгеләгән очрактан башка, бу вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен элек биләгән вазыйфасының акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктчалар өстәргә:

«9) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә;

10) төп хезмәт бурычларына юрист яки башкаручы буларак хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, аларга виза салу керә торган, югары юридик белемгә ия булган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен бирелә торган түләү түбәндәге процентлардан артмаган күләмдә:

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары | Юридик эш өчен өстәмә түләүләр күләме, вазыйфаи окладка процент |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | 8 |
| Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары | 6 |
| Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары | 4 |
| Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 2; |

11) вазыйфаи окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү:

фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен – вазыйфаи окладның 1,5 процентыннан артмаган күләмдә;

фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен – вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә.»;

14 пунктта:

3 пунктчада «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве, юридик эш өчен өстәмә түләү һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү – вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.».

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин